**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «30» маеннан № 23-170

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2005 елның 30 декабрендәге 5-27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2005 елның 30 декабрендәге 5-27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы турында нигезләмәгә (2016 елның 14 декабрендәге 20-106 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 өлешнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. «Финагнс-бюджет палатасын муниципаль район Башлыгы тәкъдиме белән район Советы тарафыннан вазифага билгеләнүче һәм вазифадан азат ителүче Рәис җитәкли. Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфасына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүче затлар билгеләнә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе вазыйфасына кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында башкарыла. Татарстан Республикасы финанс органы катнашу тәртибе «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта белән билгеләнә.

Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе районның җирле үзидарә вазыйфаи заты булып тора, районның финанс органы эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы белән килешенеп, районның Финанс-бюджет палатасы рәисе

тарафыннан билгеләнә һәм турыдан-туры районның Финанс-бюджет палатасы рәисенә буйсына.»;

1.2. 4 бүлекнең 4.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Районның Финанс-бюджет палатасы түбәндәге структур бүлекчәләрдән тора:

- керемнәр бүлеге;
- исәп һәм хисап бүлеге

Районның Финанс-бюджет палатасының структур бүлекчәләре белән бүлек башлыклары җитәкчелек итәләр һәм турыдан-туры районның Финанс-бюджет палатасы рәисенә буйсыналар.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http:/ / pravo. tatarstan. ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов